СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбјн Мјтјскј авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**28 сентябрь 2018 ел** **№ 72**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 11 номерлы "Референдум үткәрүне оештыру турында" карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 71 номерлы «референдум үткәрү инициативасы турында»гы карары нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән килешәсезме, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, бапачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерүдә катнашучыдан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: - юл полотносы һәм юл-урам челтәренә вак таш җәю.

   Иске Кырлай авылы, Һади Такташ урамы буенча 12дән 16га кадәр, 1дән 3кә кадәр;

   Өтнә авылы (Салих Сәйдәшев ур., 11дән 13кә кадәр, 1дән 3кә кадәр, Габдулла Тукай урамы буенча);

   Югары Әзәк авылы (Фәнәвил Галиев урамыннан Гомәр Бәширов урамына кадәрге тыкрык);

Түбән Мәтәскә авылы (Киров урамыннан Яшьләр урамына кадәрге тыкрык, Комсомол урамыннан Киров урамына кадәр, Тынычлык урамыннан Школьная урамына кадәр, үзәк урамыннан Татарстан урамына кадәр; 100м Тукай урамына кадәр);

Югары Мәтәскә авылы (Тукай урамы буенча 2дән 10га кадәр, Тукай урамы буенча 17дән 19га кадәр, Тукай урамы буенча 11дән 14кә кадәр);

Мөндеш авылы (Чишмә урамы буенча 13тән 18кә кадәр; 1дән 4кә кадәр, Татарстан урамыннан Чишмә урамына кадәрге тыкрыклар (300м), Татарстан урамыннан Җиңү урамына кадәр (200м);

Казиле авылы (Җиңү урамы буенча 66дан 72гәчә).

2. Җирләү урыннарын карап тоту

- Иске Иябаш авылы зираты коймасын ремонтлау (95м)

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: - Мөндеш, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә авылларында агачларны санитар кисү һәм чыгару. Экономия барлыкка килгән очракта аерым мәсьәләләр буенча рөхсәт итәргә Авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12Айорт..

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ